ГЛАВА
МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ
ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Тел.: (84375) 39-3-35; 39-4-72, факс: (84375) 39-3-35, e-mail: Mcel.Drz@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** *с.Малая Цильна* **КАРАР**

2021 нче елның 18 нче ноябре № 20

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлегенең Кече Чынлы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә белән расланган Кече Чынлы авыл җирлеге Советының 07.10.2019 ел, № 48/1 карары (15.11.2019 ел, №50/6 редакциясендә) КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлегенең Кече Чынлы торак пунктында гражданнар җыенын 2021 нче елның 08 нче декабренә 9:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Чүпрәле муниципаль районы, Кече Чынлы авылы, Крупская урамы, 2 нче йорт, Кече Чынлы авыл мәдәният йорты.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Кече Чынлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1500 сум күләмендә акча кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме?:

- Кече Чынлы авылының Казан, Чапаев, Гагарин урамнарындагы юлларга вак таш салу;
- Кече Чынлы авылының Мир урамындагы юлларын ремонтлау

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Ш.Халитов